# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 5-2** **«29» декабрь 2025 ел**

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына (ТР Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 08 сентябрендәге 57-3 номерлы, 2022 елның 24 октябрендәге 20-1 номерлы, 2022 елның 01 декабрендәге 21-3 номерлы, 2024 елның 02 июлендәге 39-1 номерлы, 2025 елның 01 ноябрендәге 42-3 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 49-6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

1 пунктта «15 389,0» саннарын «16 928,0» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс - бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Бу карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Л.Исланов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2018 елның 07 маендагы 29-1 номерлы карарына 2 нче кушымта (Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 29 декабрендәге 5-2 номерлы карары редакциясендә)

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Айлык акчалата түләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 7 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 35 893 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 32 098 |
| Депутат | 18 180 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзасы | 16 928 |